Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елның 14 октябре № 2

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Шахмай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән һәм контракт буенча хезмәт итүче гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 85 яшьтән өлкәнрәкләр, 1 төркем инвалидларыннан тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга:

- традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар кору, төзекләндерү (территорияләрне чабу, чүп үләннәрне һәм үсемлекләрне юк итү өчен акча алу, эш өчен килешү буенча түләү);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш түшәлгән авыл юллары чокырларын ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), кышкы чорда юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), җәйге вакытта юлларны чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү);

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта чабу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, уен мәйданчыгы өчен кече архитектура формалары сатып алу, урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: https://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://novosheshminsk.tatarstan.ru, бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авылындагы мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Шахмай авылы, Үзәк урам, 47 нче йорты янында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы Н.М. Илалова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ШАХМАЙКИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
р 05-11944/14
СОВЕТ ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ